ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
**«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында»**;

2) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Хокукый җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $26^{3-3}$ статьясы нигезендә түбәндәгеләрне билгели:

1) түбәндәге Татарстан Республикасы законнары проектларының, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларының, Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты карарлары проектларының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актлары проектларының (алга таба – норматив хокукый актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибен:

а) дәүләт контроле (күзәтчелеге), административ җаваплылыкка тарту, лицензияләр һәм башка рөхсәтләр бирү, аккредитацияләү, продукциянең тәңгәллеген бәяләү, бәяләүләрнең һәм экспертизаларның башка рәвешләре кысаларында үтәлеше бәяләнә торган эшкуарлык эшчәнлеген һәм башка икътисадый эшчәнлекне башкаруга бәйле мәҗбүри таләпләрнең (алга таба – мәҗбүри таләпләр) яңаларын билгеләүче, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче яисә юкка чыгаручы;

б) эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычларның һәм тыюларның яңаларын билгеләүче, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче яисә юкка чыгаручы;

в) эшкуарлык эшчәнлеген һәм башка икътисадый эшчәнлекне башкару мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын бозган өчен җаваплылык билгеләүче, элек билгеләнгәнен үзгәртүче яисә юкка чыгаручы;

2) Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларында (алга таба – норматив хокукый актлар) булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү тәртибен;

3) эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы, мәҗбүри таләпләре булган актлардан тыш, норматив хокукый актларга экспертиза ясау тәртибен (алга таба – норматив хокукый актларга экспертиза) .»;

2) 2 статьяның 2 өлешендә «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге» сүзләрен «эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 статьяның 2 өлешендә «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге» сүзләрен «эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

4) $3^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$3^1$ статья. **Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү тәртибе**

1. Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү тәртибе, «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәҗбүри

таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү принципларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2. Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү җайга салучы орган тарафыннан уздырыла.

3. Җайга салучы орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә мәҗбүри таләпләрне кертү максатларына ирешү турындагы доклад әзерли. Әлеге тәртип белән шулай ук мәҗбүри таләпләрне кертү максатларына ирешү турындагы докладны карау һәм мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актның гамәлдәге чорын озынайту турында яисә мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актның факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру турында карар кабул итү тәртибе билгеләнә.».

**Статья 2**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 60-ТРЗ